КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 июль г.Казань № 625

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында санитар-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 15 июль, 591 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Гражданнарның турыдан-туры катнашында, шул исәптән паркларда, урман паркларында һәм скверларда, сәүдә һәм сәүдә-күңел ачу үзәкләрендә (комплексларында), аттракционнарда һәм гражданнар күпләп йөри торган башка урыннарда ял итү, күңел ачу, тамаша, мәдәни, физкультура, спорт, күргәзмә, агарту, реклама һәм башка шундый чаралар үткәрү рөхсәт ителми дип билгеләргә.

Әлеге чикләү түбәндәгеләргә кагылмый:

а) музейлар, китапханәләр эшенә, шулай ук индивидуаль яки иң күбе 5 кешедән, ә экскурсия эшен алып бару өчен махсуслаштырылган радиоҗиһаз булганда иң күбе 10 кешедән торган төркемнәргә экскурсия хезмәтләре күрсәтүгә;

б) паркларндагы, скверлардагы һәм яр буйларындагы ачык мәйданчыкларда кинофильмнар күрсәтүгә;

в) ачык һавада аттракционнар эшенә;

г) ачык һавада урнашкан вольерлар өлешендәге зоопарклар эшенә;

д) профессиональ спортчыларга һәм Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең спорт төрләре буенча җыелма командалары әгъзалары – спортчыларына ачык һавада күнекмәләр ясауга;

е) гражданнарның бер үк вакытта иң күбе ике кеше катнашу һәм күнекмәләр ясаучылар арасында кимендә 5 метр ераклык булу шарты белән ачык һавада физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүләренә.

Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу шартларында профилактика чараларының үтәлешен тәэмин итә торган формада чаралар оештырырга һәм үткәрергә рөхсәт ителә.»;

9 нчы пунктның җиденче абзацына «2020 елның 13 июленнән 2020 елның 26 июленә кадәр (26 июльне кертеп)» сүзләреннән соң «2020 елның 27 июленнән 2020 елның 9 августына кадәр (9 августны кертеп)» сүзләрен өстәргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән бер көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин